КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 19 октябрь г.Казань № 939

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү процессларын гамәлгә ашырганда, шулай ук транспорт магистральләрен, үткәргеч торбаларны, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен файдаланганда хайваннар дөньясы объектлары үлүне булдырмый калу буенча таләпләр турында» 2000 ел, 15 сентябрь, 669 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү процессларын гамәлгә ашырганда, шулай ук транспорт магистральләрен, үткәргеч торбаларны, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен файдаланганда хайваннар дөньясы объектлары үлүне булдырмый калу буенча таләпләргә үзгәрешләр кертү хакында

Җитештерү процессларын гамәлгә ашырганда, шулай ук транспорт магистральләрен, үткәргеч торбаларны, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен файдаланганда хайваннар дөньясы объектлары үлүне булдырмый калу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү процессларын гамәлгә ашырганда, шулай ук транспорт магистральләрен, үткәргеч торбаларны, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен файдаланганда хайваннар дөньясы объектлары үлүне булдырмый калу буенча

таләпләр турында» 2000 ел, 15 сентябрь, 669 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 27 июнь, 255 нче, 2010 ел, 19 апрель, 273 нче; 2018 ел, 12 февраль, 76 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү процессларын гамәлгә ашырганда, шулай ук транспорт магистральләрен, үткәргеч торбаларны, элемтә һәм электр тапшыру линияләрен файдаланганда хайваннар дөньясы объектлары үлүне булдырмый калу буенча таләпләргә, 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәп, үзгәреш кертергә:

«Хайваннар дөньясы объектларының үлүен булдырмау һәм аларның яшәү тирәлеген начарайту буенча планлаштырылган чаралар Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты белән килешеп башкарыла.

Сәнәгать, су хуҗалыгы, авыл хуҗалыгы, урман сәнәгате һәм урман хуҗалыгы җитештерү процессларын тормышка ашыру, транспорт магистральләрен, объектларны һәм труба үткәргечләрне эксплуатацияләү, хайваннар дөньясы объектларының һәлак булуын һәм аларның яшәү тирәлеген начарайтуны булдырмау буенча килешенгән чаралардан башка элемтә һәм электр линияләрен проектлау, төзү һәм эксплуатацияләү рөхсәт ителми.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин